**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлегенең Төги торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

**24.11.2022** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Төги торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлегенең Төги торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча һәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Җыелган сумманы җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:
- балалар мәйданчыгы янында чәчәклек ясау;
- стела территориясен төзекләндерү;
- сабан сатып алу.

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

**Җыенда рәислек итүче,**
**җирлек башлыгы** **Т.В. Попова**